СОВЕТ
СИЗИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Школьная, д. 1, с.Смак-Корса,
Арский муниципальный район, 422025

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СЕҖЕ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ
Мәктәп урамы, 1 йорт, Курса Почмак авылы,
Арча муниципаль районы, 422025

Тел. (84366)53-2-36, факс (84366)53-2-36. E-mail: Smk.Ars@tatar.ru

**КАРАР**

**« 18 » май 2023 ел** **№ 90**

**Сеҗе авыл җирлеге Советы**
**карары**

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Сеҗе авыл җирлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен раслау турында 03.12.2021ел, №44 карарга үзгәрешләр кертү хакында**

Арча муниципаль районы Сеҗе авыл җирлеге Советының 03.12.2021 ел, №44 карарына Татарстан транспорт прокуратурасының 21.02.2023 ел, №23/1-12-23 дәгъвасы белән бәйле рәвештә, «Россия Федерациясендә тимер юл транспорты турында» 2003 елның 10 гыйнварындагы 17-ФЗ номерлы Федераль законның 1 статьясындагы 3 өлешенә яраштырып, шулай ук «Россия Федерациясе прокуратурасы турында» 1992 елның 17 гыйнварындагы 2202-1 номерлы Федераль законның 23 статьясына таянып, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Сеҗе авыл җирлеге Советы КАРАР БИРДЕ:

1. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Сеҗе авыл җирлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен раслау турында 03.12.2021 ел, №44 карарга түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1)37 нчы пунктның 5 нче пунктчасында «һәм тимер юлның» сүзләрен алып ташларга;

2) 68 нче пунктта «тимер юл» сүзен алып ташларга;

3) 69 нчы пунктта «тимер юл» сүзен алып ташларга;

4) 70 нче пунктта «тимер юл» сүзен алып ташларга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Арча муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Сеҗе авыл җирлеге башлыгы Р.В.Хамидуллин